**СОВЕТ МЕМДЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422728, Высокогорский район РТ,
с.Мемдель, ул.Кооперативная, 30

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘМДӘЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422728, ТР Биектау районы,
Мәмдәл авылы,Кооператив ур , 30

Тел./факс: +7(84365) 60-2-37, e-mail:Memdel .Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**2016 елның 4 октябре** **№ 42**

**Җирле референдумны билгеләү турында**
**Мәмдәл авылы территориясендә**
**Тукай муниципаль районы**
**үзара салым чараларыннан файдалану**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 23.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә «Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 14 статьясы, Мәмдәл авыл җирлеге Советының «референдум уздыру инициативасы турында» 2016 елның 23 сентябрендәге 39 номерлы карары, Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге Советының «референдум уздыру турында» 2016 елның 23 сентябрендәге 15 номерлы карары нигезендә

**КАРАР:**

1. 2016 елның 20 ноябренә Биектау муниципаль районының Мәмдәл авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне раслау:

«2017 елда Мәмдәл авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән акчалар белән килешәсезме:

- Юртыш бистәсендәге торак пунктта - балалар мәйданчыгы сатып алу, тирән насос сатып алу, чишмә территориясен төзекләндерү;

- Мәмдәл авылында-Г. Камал, Х. Вахит, М. Җәлил, Киров урамнарында чокырларны ямау; янгын гидранты урнаштыру.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырырга: http:// vysokaya-gora.tatarstan.ru.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Мәмдәл авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Сафиуллин